СОВЕТ
НИЖНЕВЯЗОВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРАМАЛЫ ТАУ
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**28.05.2024**

Карамалы Тау штп

**КАРАР**
**№204**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы шәһәр җирлеге Советы **карар кылды:**

1. 1 нче кушымта нигезендә җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә.
2. Түбән Карамалы шәһәр җирлеге Советының 2023 елның 26 маендагы 155 номерлы «җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Түбән Карамалы Тау штп, Беренче Май урамы, 70 йорт адресы буенча мәгълүмати стендларда, МСУ административ бинасында мәгълүмати стенд, Түбән Карамалы Тау штп, Беренче Май урамы, 70 йорт (МСУ административ бинасы).

Җирлек башлыгы,
Совет Рәисе

А.М. Гыйниятов

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы шәһәр җирлеге Советының 28.05.2024 елның 204 номерлы карарына

Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танууның өстәмә нигезләре

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләтү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч өметсез дип таныла:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танууның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) 1 пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) 1 пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) 1 пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булуы турында белешмәсе.